РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«22» апрель, 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 154

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы проектының яңа редакциясе турында

2003нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законына, 2004елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 44 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставының яңа редакциясенә таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставын кабул итәргә һәм гәвами тыңлауларга чыгарырга.

2. «Кайбыч таңнары» район гәзитендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»ның информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча түбәндәгеләрне бастырырга:

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы проектын яңа редакциядә (Кушымта № 1);
- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы проектының яңа редакциясенә гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе һәм гражданнарның аны тикшерүдә катнашуы тәртибе (Кушымта № 2);
- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль

берәмлеге Уставы проектының яңа редакциясе буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе (Кушымта № 3).

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карары проекты буенча килә торган тәкъдимнәр исәпкә алу, гомумиләштерү, карау буенча түбәндәге составта эшче комиссия төзергә:

Лазарев С.В. – төркем җитәкчесе, төркем әгъзалары – Нигъмәтҗанов Ф.Т., Садриев М.Р., Бәдертдинова Д.А., Кузнецова Р.Ф.

4. Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар урамы, 7нче йорт адресы буенча урнашкан Җәмәгать үзәгендә 2019елның 13 маенда 10:00 сәг тә гавами тыңлаулар үткәрергә.

5. Эшче төркемгә Кайбыч муниципаль районы Советы депутатларының һәм гражданнарның «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы проектының яңа редакциясе буенча тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә.

6. Кайбыч муниципаль районы Советы Аппаратына һәм Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына күрсәтелгән проектның гавами тыңлауларын үткәрүне, гражданнардан тәкъдимнәр исәпкә алу, гомумиләштерүне тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Советы рәисе урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И. Рәхмәтуллин